БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №19 (7036) | 15 февраль, 1990 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

**Кичә Мәскәүдә СССР Верховный Советы сессиясе үзенең эшен башлады**

## СССР Верховный Советы сессиясе ачылу

МӘСКӘҮ (ТАСС). 14 февральдә Кремльдә Союз Советы һәм Милләтләр Советының берләштерелгән утырышы белән СССР Верховный Советының өченче сессиясе үзенең эшен башлады. Сессияне кереш сүз белән СССР Верховный Советы Председателе М. С. Горбачев ачты.

Сессиянең көн тәртибе күптөрле һәм тыгыз. Биредә 50 мәсьәләне карау күздә тотыла, аларның 20 се беренче чиратта тикшерүгә мохтаҗлар. Көн тәртибендә СССР Верховный Советы Президиумының якын көннәрдә СССР халык депутатларының чираттан тыш Съездын чакыру турындагы тәкъдиме дә бар. Аны чакыру СССР Конституциясенә политик система, хосусыйлык, Совет дәүләтен ныгыту мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү һәм безнең илебездә демократик власть булдыру мәсьәләсен карау зарурлыгы белән аңлатыла.

Сессиядә хосусыйлык, җир турында, социалистик предприятие, налог системасы, җирле үзидарә һәм җирле хуҗалык итүнең уртак башлангычлары турындагы фундаменталь экономик Закон проектларына һәм социаль пландагы әһәмиятле Закон проектларына зур игътибар биреләчәк.

Милли политика стилендә законны яңартуның аерата актуальлеген искә алып, Верховный Совет комитетларында һәм палаталарның даими комиссияләрендә кайбер проектлар каралачак. Алар — ССР Союзы һәм союздаш республикалар арасындагы вәкаләтләргә чик үткәрү, СССР Конституциясенең 72 нче статьясына туры китереп союздаш республиканың ССР Союзы составыннан чыгуы белән бәйле мәсьәләне хәл итү тәртибе турында проектлар. Депутатларга шулай ук гражданнарның милли тигезлегенә кул күтәргән һәм СССР территориясенең бердәмлеген бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында Закон проектын тикшерергә дә туры киләчәк.

Шулай ук хөкүмәт тарафыннан тәкъдим ителгән дәүләт налог инспекциясе хокуклары, гадәттән тыш хәл хокук режимы турында һәм СССР эчке эшләр министрлыгы эчке гаскәрләренең җәмәгать тәртибен саклауда хокуклары һәм бурычлары турында Закон проектларын карау да тәкъдим ителә. Тиешле комитетлар һәм комиссияләр әлеге Закон проектлары буенча үз нәтиҗәләрен тапшырдылар. СССР халык депутатларының II Съезды карарлары нигезендә, сессия СССР Верховный Советының җинаятьчелеккә каршы көрәш мәсьәләләре буенча комитетын сайлаячак. СССР Верховный Советы Президиумының сессиянең эш тәртибенә карата тәкъдимнәре белән утырышта СССР Верховный Советы Председателенең беренче урынбасары А. И. Лукъянов чыгыш ясады. Ул сессия каравына СССР Верховный Советы Президиумының СССР халык депутатларының чираттан тыш III Съездын 27 февральдә чакыру турында тәкъдимен кертте.

СССР Верховный Советы сессиясе үзенең эшен апрель азагында тәмамлар дип көтелә.

### ЗУР ТЫРЫШЛЫК КУЕП

**«40 лет Победы» колхозы.** Товарлыклы-дуңгызчылык фермасы коллективы елны уңышлы башлады. Фермада һәр дуңгыз караучы мактауга лаек. Шулардан Валентина Анисимова, Марина Щпалова, Евгения Мельникова, Валентина Никитина турында аеруча әйтеп үтәргә кирәк. Алар һәркайсы яшьтән фермада хезмәт куялар. Тәҗрибәле терлекчеләр карамагындагы малларның январь аенда уртача тәүлеклек артымы 383 граммга җитте.

### АШХАНӘ АЧЫЛДЫ

Товарлыклы-дуңгызчылык фермасында ашханә ачылды.

Колхозчылар өчен авыр хезмәттән соң җылы, чиста, матур бизәлешле ашханәгә кереп ял итү үзе бер канәгатьләнү. Анда аларны җылы ашлары һәм якты йөзләре белән пенсионерлар Антонина Федоровна Анисимова һәм Мария Ивановна Сухова каршы алалар.

**Ф. СИТДИКОВ.**

## Язучылар бездә кунакта

Үткән көннәрдә генә районыбызда СССР Язучылар союзы членнары — прозаик Мәгъсүм Хәмитович Хуҗин, шагыйрь һәм прозаик, «Казан утлары» журналы хезмәткәре Нияз Рәшитович Акмалов булдылар һәм хезмәт коллективлары белән очрашулар үткәрделәр.

12 февральдә «Дуслык» район газетасы хезмәткәрләре белән очрашу барышында бүгенге совет әдәбияты, аның алдында торган проблемалар, журналистларның бүгенге бурычлары турында эчкерсез сөйләшү булып үтте.

13 февральдә кунаклар район китапханәсендә культура работниклары, әдәбият сөюче һәм башлангыч иҗат белән шөгыльләнүче яшь авторлар белән очраштылар.

Мөгезле эре терлекләр симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә очрашу вакытында совет әдәбияты турында эчтәлекле сөйләшү барды. «Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең яшь эшчеләре, инженер-техник работниклары белән очрашу барышында нигездә әдәбиятта бүгенге проблемаларга кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде.

Һәр урында очрашулар барышында язучылар хезмәт иясләрен кызыксындырган культура һәм әдәбият үсешенә кагылышлы сорауларга җаваплар бирделәр.



**Евгений авыр хезмәтләрнең берсен сайлады — ташчы булды. Аның уйлавынча, чын ир кеше җиңел юлны эзләмәскә тиеш.**

**Беренче көннәре Евгенийга җиңел булмады, әлбәттә. Эшнең нечкәлекләренә төшенү соралды, төрле кыенлыклар килеп чыкты. Тик бу сынауны ул уңышлы үтте һәм хәзер үзе 53 нче төзү-монтаж идарәсендә тәҗрибәле ташчыларның берсе булып санала.**

**Тырышлыгы, карусыз булуы өчен хезмәттәшләре дә хөрмәт итәләр үзен.**

**Рәсемдә: сез ташчы Евгений Григорьевич Макаровны күрәсез.**

**КПСС Үзәк Комитеты платформасы: фикерләр һәм тәкъдимнәр**

## Принципиаль сөйләшү барды

**КПСС Үзәк Комитетының февраль (1990 ел) Пленумы барышын коммунистлар, барлык хезмәт ияләре зур кызыксынучанлык һәм өметләр белән күзәттеләр. Партиянең XXVIII съездына кабул ителгән платформа аларның күбесенең бүген бик актуаль булган сорауларына җавап бирде. Шушы уңайдан редакция район партия оешмасының аерым вәкилләренә мөрәҗәгать итте һәм истәлекле бу Пленум турында үз фикерләрен белдерүләрен сорады.**

Партия Үзәк Комитетының бу Пленумының башкалардан аермалы ягы — югары ранг җитәкчеләренә конкрет һәм туры тәнкыйть фикере әйтелә. Элгәре мондый пленумнарда бүгенге кебек ачыктан-ачык сөйләшү булмый торган иде. Бүгенге көнгә, ниһаять, анда катнашучы коммунистлар исеменнән илебездә яшәп килгән башка политик оешмалар турында әйтелде, алар белән компромисска керү кирәклеге күрсәтелде. Күп ораторлар демократик централизм принцибын бүгенге шартларга җавап бирерлек итеп үзгәртү, башлангыч партия оешмаларының ролен күтәрү кирәклеген бик дөрес яклап чыктылар.

Литва Коммунистлар партиясенең XX съезды карарларына мөнәсәбәт мәсьәләсендә Пленум кабул иткән карар белән килешә алмыйм. Дөрес, анда Литва коммунистларының бу адымы гаепләнде, КПСС платформасында калган Компартиягә ярдәм итү кирәклеге күрсәтелде. Ләкин бу гына аз. Литваның мөстәкыйль Коммунистлар партиясе төзү турындагы карары КПСС Уставы нормаларына берничек тә сыймый, алар фактта безнең белән элемтәләрен өзделәр инде. Шулай булгач, аларны үгетләп торуның кирәге юк, компромисс эзләү дә булмаска тиеш.

**Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ,**
Ульяновск тимер юл депосының Норлат филиалы партия оешмасы секретаре.

## Фикерләренә кушылам

Илебез башкаласы Мәскәүдә үткән КПСС Үзәк Комитеты Пленумында фикер алышуда катнашучыларның күбесенең чыгышлары ошады. Алар нигездә халыкны борчыган проблемаларны күтәрделәр, алга таба нишләр эшләргә кирәклегенә басым ясадылар, үзләренең конкрет тәкъдимнәрен керттеләр. Аеруча КПСС-ның Киев шәһәр комитеты беренче секретаре Г. И. Ревенконың чыгышы күңелгә якын булды.

Пленумда, партия, совет органнары работникларының хезмәт хакларының күтәрелүенә ризасызлык белдерелде. Шуңа да бу мәсьәләне яңа баштан карау кирәк дип саныйм.

Аннары СССР Конституциясенең 6 статьясын тагын бер кат җентекләп карарга һәм тикшерергә кирәк.

**Ә. ШӘЯХМӘТОВ,**

**Бүгенге санда**

**КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ПЛАТФОРМАСЫ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШАБЫЗ.**

**ДЕПУТАТЛЫККА КАНДИДАТЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛИБЕЗ.**

**ХАКЛЫК ҖИҢӘР.**

**Идеология эшен—үзгәртеп кору таләпләре югарылыгына**

# Диалог—чынбарлыкны тану юлы

Геофизик эшләрнең Норлат идарәсендә Виктор Михайлович Халипа үткәргән һәр занятие коммунистлар һәм партиясез тыңлаучылар арасында да зур кызыксынучанлык һәм активлык уята. Идарәдә шактый еллар пропагандист вазифасын үтәүче Виктор Михайлович моңа һәр занятие диалог—пропагандист һәм тыңлаучылар арасында теге яки бу тема буенча фикер алышу, диспут юлы белән ирешә. Тема буенча аны анализлау барышында бәхәсләшү аркылы тыңлаучылар хакыйкатькә киләләр.

Һәм әйтергә кирәк, район пропагандистларының күбесе политик мәгариф челтәрендә укулар барышында диалог алымын торган саен киңрәк кулланалар. Элек популяр булган лекция белемнәрне пропагандалауның формасы буларак искерде, идеология эшен үзгәртеп кору бу юнәлештә дә яңа формаларны киң куллануны таләп итә. Шуңа пропагандистлар эзләнәләр, илдә бара торган үзгәрешләрне теоретик нигезлиләр, аңлаталар, күмәк фикер алышу барышында тыңлаучыларны инандыралар. В. Е. Ефимов (райфо), А. С. Магин («Россия» колхозы), Р. Ш. Әһлиуллин (хуҗалыкара берләшмә) һәр занятиедә үз алдына шундый максат куеп эшлиләр. Һәм моның тыңлаучыларга рухи тәэсире зур.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр производствога да йогынты ясый. Тормыш хуҗалык итүнең яңа, экономик яктан нигезләнгән хуҗалык исәбенә бәйле формаларын кертүне таләп итә. Кыскасы, экономика өлкәсендә дә яңача фикерләү, тармакның үз исәбенә яши алу мөмкинлеген конкрет эш мисалында ачып бирү зарури. «Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе пропагандистлары Ф. Х. Зарипова, Ә. Р. Әбҗәббарова идарә эшчәнлеген экономик күзлектән чыгып анализлыйлар. Теге яки бу подразделение, цехта яңача хуҗалык итү принциплары турында производствоның бүгенге торышын тыңлаучылардан анализлаталар, аларны экономиканы чагылдыручы саннар белән ныгыталар. Яңалыкка да алар пропагандистның юнәлеш бирүче сораулары аркылы эзләнә-эзләнә киләләр. Яңалыкны эзләү турында сүз алып барганда, Норлат-Октябрь автопредприятиесе пропагандисты В. В. Кадыйров тәҗрибәсе дә игътибарга лаек. Занятиеләр барышында үзләрендә эшләүче арендачы шоферларның хезмәт нәтиҗәләре белән кызыксына, тыңлаучыларга аларны җиткерә. Бу, әлбәттә, шоферлар һәм инженер-техник работниклар арасында кызыксынучанлык уята, сораулар үзеннән-үзе килеп туа.

Диалог методының заруриылыгын тормыш үзе таләп итә. Җәмгыятьтә үзебезнең үткәнебезне, бүгенгене һәм киләчәкне яңадан анализлау бара, кешеләр аңында яңа караш формалаша, яңача фикерләү туа. Бу процессның асылында ленинизм принципларында социализмның яңаруын аңлату кирәк. Бүген аерым катлам хезмәт ияләрендә партиягә ышаныч кимегән вакытта моңа төшендерү аеруча мөһим. Моның өчен пропагандистның үзенең дә тиешле дәлилләр һәм фактлар белән коралланган, үзгәртеп коруларны алып баруда партия политикасының дөреслегенә инанган булуы зарури. Занятиеләрнең максатка ирешүе пропагандистның хәзерге шартларда партиянең эчке политикасының төп юнәлешләрен яхшы үзләштерүенә дә күп бәйле. Аңа Татарстан партия оешмасының 4 мартта үтәчәк халык депутатларын сайлау алды платформасын, КПСС Үзәк Комитетының милли мәсьәләләр буенча сентябрь (1989 ел) Пленумы карарларын, XXVIII съездга хәзерлек барышында «Правда» газетасы битләрендә җәелдерелгән дискуссия материалларын, М. С. Горбачевның «Социалистик идея һәм революцион үзгәртеп корулар» мәкаләсен белү, агымдагы вакыйгалар барышы турында хәбәрдар булу кирәк. Аның шулай ук СССР халык депутатларының I, II Съездлары, СССР Верховный Советы, аның комиссияләре эше турында да тыңлаучыларга тиешле аңлатма бирерлек хәзерлеге булуы шарт.

Тыңлаучылар белән диалог —реаль чынбарлыкны танып-белергә, хакыйкатькә килергә ярдәм итүче, халык белән аңлашуның актив формаларыннан берсе. Шуңа һәр пропагандистка аны киң куллану тыңлаучыларга материалны аңлатуның, аларның теманы ныклы үзләштерүенең ышанычлы юлы булуын истән чыгарырга ярамый, чөнки әлеге форма идеология эшенең иң үтемле чарасы бүген.

**В. КОРМУХИН,**
КПСС райкомының политик мәгариф кабинеты каршындагы методик совет председателе.



Аларны укучылар белән таныштырабыз: Нина Ивановна Сидуллина (сулда) —Мичурин исемендәге колхоз бухгалтеры, Нина Васильевна Вурмандеева —Урта Камышлы фельдшер-акушерлык пункты мөдире.

Икесе дә авыл интеллигенциясе категориясе хатын-кызлары. Безнең халык интеллигенциясеннән алар тамырлары белән җиргә береккән булулары ягыннан аерылып торалар. Аларның психологияләрен ахырга кадәр аңламаган кебек, шәһәрдә яшәүчеләр алардан көнләшә дә алмыйлар. Аларга табигать тарафыннан икмәк һәм безнең өстәлләр муллыгын тәэмин итүче барлык нәрсәләрнең ничек җитештерелүен белүдә, крестьян нәселен дәвам итүдә, җирне хуҗасыз һәм дәвамсыз калдырмауда өстенлек бирелгән.

Нина Ивановна һәм Нина Васильевна үзләренең төп хезмәт вазифаларыннан тыш хатын-кызлар советы вәкилләренең югары хокукларына ия. Беренче тапкыр сайланганга күрә гаиләгә, балаларны тәрбияләүгә, авылда хатын-кызлар хезмәтен яхшыртуга, аналарны һәм балаларны саклауга тәэсир итүнең төрле формаларын һәм юлларын эзлиләр.

Хатын-кызлар советының авылда яшәүче халык мәшәкатьләре һәм ихтыяҗлары тәэсирендә туган конкрет эш планы бар. Совет члennары күп балалы гаиләләрнең тормыш-көнкүреш шартларын тикшерәләр, ялгыз картларга һәм карчыкларга ярдәм итәләр. Мәктәптә даими булалар, укыту-тәрбия процессы белән танышалар, мәктәп ашханәсенең санитар торышын тикшерәләр һәм башкалар. Киләчәктә хатын-кызлар советы белән ата-аналар комитетының куәтен берләштерү күздә тотыла. Бу юнәлештә ике ул тәрбияләгән Нина Ивановна һәм өч бала анасы Нина Васильевнаның да бай тәҗрибәләре һәм кызыклы уйлары бар. Социаль тормышта хатын-кызлар потенциалының активлыгы чагыла торган тагын бер өлкә бар. Бу—авыл үзешчән сәнгате. Авыл культура йорты каршындагы «Уяв» («Хороводы»)—фольклор ансамбле коллективларының Бөтенроссия смотры лауреаты. Иҗат коллективының биографиясе кызыклы, буыннан-буынга тапшырыла торган традицияләре көчле.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: ансамбльдә Нина Васильевнаның ире, комплексны бригада бригадиры Юрий Сергеевич та чыгыш ясый. Ансамбльнең төп нигезе булып хатын-кызлар—хезмәтчелләр, үзешчән артистларның беренче буыны тора. Болар —бозау караучылар Елизавета һәм Зоя Захаровалар, Зоя Кузьмина, Раиса Сидорова, мәктәп ашханәсе пешекчесе Вера Андреева һәм мәктәп җыештыручысы Роза Васильева һәм башкалар.

Авыл Советы башкарма комитеты —аның секретаре Зоя Ивановна Левакова һәм хатын-кызлар советы «Уяв»ның барлык иҗади башлангычларын кызыксынып яклыйлар, аңа тулы канлы тормыш белән яшәргә булышалар. Хатын-кызлар советы торак пунктларны төзекләндерү һәм чисталыкта тоту өчен актив көрәшүне үзенең бурычы итеп саный. Һәм, әйтергә кирәк, моны эшли дә ул. Юкка гына камышлылар авылларның санитар торышы буенча «иң яхшылар» рәтенә чыкмадылар.

**Безнең кандидатлар**

# Гади, авылча

«Россия» колхозы хезмәтчәннәре үзләренең җыелышларында Ю. В. Терентьевның ТАССР халык депутатлыгына кандидат итеп товарлыклы-дуңгызчылык фермасы мөдире Ю. Г. Саврандейкинаны күрсәтүен бертавыштан яклап чыктылар.

Ни өчендер, күптәннән күреп белгән кеше турында сөйләве һәрчак кыен. Бер караганда, Юлия Германовнаның биографиясендә дә искитәрлек әлләни юк сыман. Егоркино урта мәктәбен тәмамлаган. Авылдан кая булса да китү турында теләк аның уенда да булмаган. Алабуга шәһәрендә берьеллык курсларны тәмамлаганнан соң, туган колхозында ветеринар-техник булып эшли. Ике ел инде товарлыклы-дуңгызчылык фермасына җитәкчелек итә. Теләсә кайсы башка барлык коллективлардагы шикелле, монда да аның үз проблемалары, кыенлыклары бар. Шуңа да карамастан, ул районда алдынгылар исәбендә. Күрәсең, моңа кешеләрнең тупланганлыгы, җитәкче тәэсире, коллективта аеруча кыйммәтле дуслык төшенчәсен саклый алу, ярдәмгә килергә әзер тору кебек сыйфатлар сәбәпчедер. Ә Юлия Германовнаның характеры тыныч, конфликтлы ситуацияләрне бастырырга сәләтле. Ул хезмәт коллективы интересларын яклый белә, ә инде иң мөһим кайгыртучанлыгы булып хезмәт шартларын һәм терлекчеләрнең көнкүреш шартларын яхшырту бурычы кала. Аны коллектив члennарының яшәү шартлары да кызыксындыра. Нигә дигәндә, аларның иң зур күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итә бит.

Юлия зур һәм тату гаиләдә туып үсте. Хезмәт сөючәнлегенең төбе-тамыры да нәкъ әнә шунда. Боларның һәммәсе аны яңа хезмәт көненә җилкендерә. Бертөрле сыман тоелган эш көннәреннән соң, аңа сиздермичә авылдашлары тарафыннан хөрмәт килде һәм, нәтиҗә буларак, депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр.

Бу көннәрдә ул колхоз хезмәтчәннәре тарафыннан күрсәтелгән ышанычны аклау өчен тагын да зур тырышлык белән һәм җаваплылык хисе тоеп эшли.

**А. МАГИН,**
Егоркино урта мәктәбе директоры.

# Эшлекле кешеләр токымыннан

Кешенең бөтен табигатен, холык-фигылен ачыклаучы бер сыйфаты була. Роза Рәгыйповна турында сүз барганда, гадәттә иң элек аны принципиаль һәм дөреслекне яклаучы буларак телгә алалар. Гадәте шундый Розаның: хаксызлыкны сөйми, дөреслекне күзгә бәреп әйтүчән. Һәм тагы бер сыйфаты—сүзендә тора белә: әйттеме—үти, хәленнән килмәгән вәгъдәне аңардан каерып та алам димә. Мөгаен, үзе эшли торган коллективта —ә ул халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең район производство идарәсендә юристконсульт—зур хөрмәт яулавының сере дә шундадыр. 9 ел эшли инде ул биредә. Башта кадрлар бүлеге инспекторы булды, читтән торып Чиләбедәге юридик техникумны тәмамлады. Шулай итеп, бай тормыш тәҗрибәсенә юридик белем дә өстәлде. Шуңадыр да, юристконсульт эшенә күчкәч тә Роза Рәгыйповна зур кыенлыклар кичермәде. Социаль гаделлек, хезмәт ияләренең законлы хокукларын яклау, хезмәт мөнәсәбәтләрендә дөреслекне саклау аның өчен иң төп максат булып калды. Боларга Розаның күп еллар буе профком члены булуы да зур ярдәм итте. Кешеләрне тану, аларга якын килә белү кебек сыйфатларны нәкъ җәмәгать поручениеләре тәрбияли дә бит. Хәзер исә Роза Рәгыйповна профсоюз комитеты председателе вазифасын да уңышлы алып бара. Ана, хатын-кыз буларак, коллективның төп эшче көчен тәшкил итүче хатын-кызлар хезмәтен җиңеләйтү, аларның сорау-үтенечләренә игътибарлы булуы өстенә, һәр кеше күңеленә юл таба белүен дә өстәргә кирәктер. Эрудицияле, грамоталы белгеч кешелеклелек сыйфатларын һәрчак беренче планда тота. Роза Рәгыйповна Октябрь район халык судында халык утырышчысы буларак та хөрмәтле.

Р. Р. Азюкованы безнең хезмәт коллективы халык депутатларының шәһәр Советына халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтте. Халык тәкъдимен кире кагарга күнмәгән Роза моңа ризалык бирде. Ә сайлау алды платформасын төзегәндә, без янә үзебезнең Розага карап сокланмый булдыра алмадык: реаль булсын, буш вәгъдә биреп йөз кызарырга калмасын— кандидатның төп критерие әнә шундый инде. Шуңа да вәгъдәләре башкаларныкы белән чагыштырганда тыйнак та, җыйнак та килеп чыкты. Әмма без аларның үтәләсенә, Розаның халык ышанычын аклау өчен белемен дә, сәләтен дә кызганмаячагына бүгеннән ышанабыз. Чөнки Роза Рәгыйповна Азюкова—эшлекле кешеләр токымыннан, ул сүзенең эштән аерылмавын максат итеп яши.

**Р. КАМАЛОВА,**
кадрлар бүлеге инспекторы.

# Хакыйкать бәхәстә туа

БХСС сотрудниклары катнашы белән райпо универмагының «Галантерея» бүлегендә тулы инвентаризация үткәргәндә, ярдәмче бүлмәдә 118 мең 180 сум күләмендә инкассациягә тапшырылмаган акча табыла. Былелның 31 январенда 22 сәгать 30 минутта райпо кассасында янгын чыга. Бу хакта район газетасының 6 февраль санында басылган иде инде. Бу урында район эчке эшләр бүлеге начальнигы иптәш В. В. Ивановның аңлатмасын әйтеп китәсе килә.

«1990 елның 24—26 январьларында район эчке эшләр бүлеге инициативасы буенча райпо универмагының «Галантерея» бүлегендә БХСС сотрудниклары катнашында инвентаризация үткәрелгән иде. Бу алтын әйберләренә хөкүмәт бәяләре күтәрелгәч эшләнде. Инвентаризация нәтиҗәсендә 93 тиен җитешмәүчәнлек беленде. Инвентаризациянең беренче көнендә ярдәмче бүлмәдә 118 мең 180 сум күләмендә инкассациягә тапшырылмаган акча табыла. Кибеттәгеләрнең аңлатуы буенча товар сатудан алынган керем товар әйләнешен көйләү өчен яшерелгән булган.

31 январьда «Кооппромторг»ның барлык кибетләрендә дә комплекслы инвентаризация уздырыла. Инвентаризация вакытында «Ветеран» кибетендә 1.600 сум җитешмәүчәнлек беленә. Кибет мөдире В. Корнева ул сумманы кассадан алып үзенә йомшак мебель алу өчен кулланган. Җитешмәгән сумманы кибет кассасына инвентаризация вакытында керткән.

Ремтехпредприятие янындагы промышленность товарлары кибетендә инкассациядән яшерелгән 22.900, шикәр заводы кибетендә 27.800 сум акча барлыгы беленә.

31 январьдагы инвентаризация көнендә «Кооппромторг»кибетләре 67800 сум керем, ягъни барлык кибетләрнең 1,5 көнлек (бу көнне алар 13 сәгатькә кадәр генә эшләделәр) товар саткан кереме кадәр акча алынды.

Инкассатордан яшерелгән акчалар факты буенча БХСС тикшерү эше алып бара. Әлегә бу фактка юридик бәя бирелмәгән. Җентекле тикшерү алып бару өчен вакыт таләп ителә: китерелгән зыянның күләмен билгелисе бар. Ә моның өчен ул акчаның яшерелгән вакыты һәм башка фактлар кирәк. Тикшерү вакытында җинаять составы расланса, гаеплеләр закон нигезендә җавапка тартылачаклар».

Сәүдә эшендәге хуҗасызлык, башбаштаклык шәһәр халкын гына түгел, бөтен район кешеләрен борчуга салды, алар арасында ризасызлык тудырды, төрле уйдырмалар китереп чыгарды. Шул уңайдан идарә членнары җыела, хәл анализлана һәм карар да чыгарыла.

Идарәнең 30 январендә үткән бу утырыш түбәндәге карарга килә:

1. Сәүдә кагыйдәләрен, сатудан кергән керемне тапшыру срогын тупас бозган, керемнәрне (аеруча зур сумнарда) туплап тоткан өчен, бүлек мөдире М. А. Шәрәфетдинова, бригада членнары Г. А. Рамазанова, Н. Ә. Әхмәтшина, Л. И. Гришаева, Р. Ф. Шәйхединова, В. В. Васильева составындагы «Галантерея» бүлеге бригадасын эштән алырга,«Кооппромторг»директоры В. В. Чванова, директор урынбасары С. Г. Митяева иптәшләрне хезмәт вазифаларыннан азат итәргә.

2. Райпо һәм «Кооппромторг» аппаратының калган хезмәткәрләре җаваплылыгы турындагы мәсьәләне «Кооппромторг» магазиннарында тулы инвентаризация йомгакларыннан соң карарга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне райпо председателенең сәүдә буенча урынбасары Х. Х. Садыйковка йөкләргә.

Шушы карар кабул ителгәннән соң «Кооппромторг»ның барлык кибетләренә инвентаризация башлана һәм ул ике көн дәвам итә. Инвентаризация төрле кибетләрдә сәүдә кагыйдәләрен төрлечә бозу фактларын ачыклый.

Шушы хәлләрдән соң, 1990 елның 5 февралендә райпо правлениесе утырышында «Кооппромторг» кибетләрендә үткәрелгән инвентаризация йомгаклары карала. Утырышта аның нәтиҗәләре буенча түбәндәге карар кабул ителә:

1. «Кооппромторг»ның 1 нче кибете мөдире Е.С. Илюшкинага сәүдәдән кергән акчаны вакытында тапшырмавы, зур күләмдәге керемне тотып калганы өчен шелтә белдерергә, бригада членнарын 1990 елның январь ае премиясеннән тулысынча мәхрүм итәргә.

Универмагның аяк киемнәре бүлеге мөдире Л. Е. Филиппова һәм бригада членнарына эштә саксызлыкларына күрсәтергә. Алар моның нәтиҗәсендә 487 сум 05 тиен җитешмәүчәнлеккә юл куйганнар. Әгәр мондый фактлар кабатланса, аларга карата катгый чаралар кулланылачак.

Каршы сату кибете мөдире А. Гыймалетдиновага үз эшенә җавапсыз каравын билгеләп үтәргә һәм кибеттә эшне тиешле дәрәҗәдә оештыруны йөкләргә;

«Ветеран» кибете мөдире В. Корневаны 1063 сум 47 тиен акча үзләштергәне, сәүдәдән кергән керемне вакытында тапшырмавы өчен эштән азат итәргә, сатучы В. Фадеевага шелтә белдерергә, 1989 ел йомгаклары буенча премиядән мәхрүм итәргә.

4 нче кибет мөдире В. Вәлиевага зур суммадагы акчаны тапшырмый калдырганы һәм сәүдәдән кергән акчаны вакытында тапшырмавы өчен шелтә белдерергә, бригада членнарын 1990 ел январе премиясеннән тулысынча мәхрүм итәргә;

2. Сәүдә керемен тапшыруга контрольлек итмәве, кооператив милкен саклауны тәэмин итмәгәне өчен «Коопродторг»ның өлкән бухгалтеры Б. Г. Кузьминага шелтә белдерергә.

Кооператив средстволарын саклауны тәэмин итмәве, сәүдә керемен тапшыруга контрольсезлеге, инвентаризация үткәрү кагыйдәсен һәм инструкцияне бозганы, бер үк бүлектә шул үк ревизорларның берничә тапкыр инвентаризация ясауларына юл куйганы өчен, райпоның КРО начальнигы Н. Ф. Литвинованы эшеннән азат итәргә.

3. Идарә председателе урынбасарларының җаваплылыгы мәсьәләсен Татпотребсоюз правлениесе карамагына бирергә.

4. Әлеге карарны райпоның барлык прилавка работникларына җиткерергә һәм сәүдә предприятиеләре коллективларында тикшерергә.

5. Кабул ителгән карарның үтәлеше өчен контрольлекне райпо председателенең кадрлар буенча урынбасары Ф. М. Җамалиева һәм сәүдә буенча урынбасары Х.Х. Садыйковка йөкләргә».

Билгеле, беркемнең дә гаепне үз өстенә аласы килми. Биредә дә шулай булды. Сәүдә кагыйдәләрен бозучылар судан коры чыгарга уйладылар булса кирәк. Алар шикаять белән КПСС райкомының беренче секретаре иптәш Х. Х. Морадыймов янына агылдылар. Бюро членнары бергәләп сөйләшкәннән, киңәшкәннән соң, бу мәсьәләне шәһәр халкы карамагына куярга, ачыктан-ачык сөйләшү алып барырга карар кылынды. Һәм 7 февраль кичке 17 сәгатьтә шәһәр предприятиеләре, оешмалары коллективлары эшче контроль группалары членнары, җәмәгатьчелек, барлык сәүдә хезмәткәрләре катнашында киңәшмә үткәрелде.

Сөйләшүне КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов ачты. Ул әлеге җыелышны чакыру сәбәпләрен аңлатты һәм райпо системасында килеп туган хәлне ачыклауда катнашырга чакырды. Аннан соң иптәш Морадыймов шәһәр халкыннан үз исеменә кергән хатларны укыды, аларга тиешле кешеләрнең җавап бирүләрен сорады. Ачыктан-ачык сөйләшү булгач, кешеләрне әлеге хатлар белән дә таныштырыйк инде.

«Без, универмаг сатучылары,—дип язалар бер төркем кибетчеләр. —Сездән правлениенең Чванова һәм Митяеваны эштән азат итү турындагы карарын үзгәртүсез калдыруыгызны үтенәбез. Бу карар белән тулысынча килешәбез. Чөнки барысына да Чванова белән Митяева гаепле. Алар бүлекләрдән даими рәвештә әҗәткә акча, товар алып тордылар, икесе дә кассадагы акчаның вакытында тапшырылмавын беләләр иде. Безне сезнең каршыга барырга, аларны эш урыннарында калдыруны сорарга мәҗбүр иттеләр. Без аларның эш урыннарында калуларын теләмибез. Ләкин ачык сөйләргә куркабыз. Чванова райкомнан кайткач, безнең белән әңгәмә үткәрде һәм бүген, иртәгә булачак җыелыш алдыннан да җыйды. Һәм монысы да бар: Митяевага нәрсәгә нигезләнеп квартира бирделәр икән: ул бит ялгыз, әти-әнисе янында аерым яши иде. Бездә күпме аналар балалары белән тулай торакларда яшиләр. Әфганстанда интернациональ бурычларын үтәп кайтучылар бар. Ә аның өстенлекләре нәрсәдә? Ул бит Әфганстанда булса да сугышмады, кан коймады».

Митяевага квартира, дөресрәге, бүлмә бирүне райпоның профком председателе Т. В. Илялова аңлатты. Бер бүлмәле квартирага кирәргә теләүчеләр булмагач, аңа биргәннәр, янәсе. Хат азагында фамилияләр юк, ул коллектив исеменнән. Шунысы характерлы, Чванова да, Митяева да хатта язылганнарда хаклык юк дип күтәрелеп чыкмадылар, һәр хатны дикъкать белән тыңлап утырдылар.

Җыелышта халыкка игълан ителгән тагын бер хат. Аны НГДУ хезмәткәрләре язган.

«Хәлил Хәмзиевич! Сәүдә эшендәге тәртипсезлекләр кайчан бетәр? Рәшидов, Брежнев һәм башкалар турында гел сөйлибез, ә үзебезнең борын астындагыларны күрмибез. Бүген бөтен Норлатта, алай гына да түгел, бөтен районда сәүдәгәрләребез турында сүз йөри. Әллә кайчан фаш итәргә иде аларны. «Галантерея» бүлеге мөдире М. Шәрәфетдинова алтынның бәясен арттырып сату белән шөгыльләнде. Өеннән яки туганнары аша танышларына бирде. Бүлмәләрен чит ил мебельләре белән нәрсә хисабына җиһазлады, балаларын матур киендерде? Миллионлаган хезмәт хакы алмый бит. Ә ире инвалид.

Бу эшне сез яшереп калырга уйлыйсыз диләр. Әгәр аны, Чванованы, Сафинны эштән алмасагыз, Шәрәфетдинованы суд җаваплылыгына тартмасалар, районда хәл Волгоградтагыдан ким булмаячак. Халык чиктән тыш дулкынланган. Кемнедер тиеннәр өчен утырталар, ә монда меңнәрне яшереп яталар. Моның өчен бар җиһазларын конфискацияләргә кирәк. Бу безнең наказ».

Бүгенге җыелыш хат авторларын канәгатьләндергәндер. Гаеплеләрне яшереп калдырырга маташучы юклык расланды биредә. Тик алар кемнәр икән соң? Беркем дә үзен гаепле итәсе килми бит әле. Район эчке эшләр бүлеге начальнигы иптәш Иванов әйткәнчә, вакыт күрсәтер.

Хатларның берсендә «Ни өчен райпода «туганлык» тамыр җәйгән? Югары Норлат ваклап сату сәүдә предприятиесе директоры Мельниковның хатыны райпо экономисты З. И. Горшкованың туганнан туганының кызы универмаг сатучысы, тагын бер туганының кызы КРО начальнигы. Ә Дмитриевскаяның туганы универмагның аяк киемнәре бүлегендә»,— дип язалар.

Шунда ук райпо хезмәткәрләренең кибеттән алган товарларын ошамаса кире китерүләре, Чванованың аларны үз кабинетына алып килүе, үз дигәннәренә бирүе турында әйтелә. Хатка имзаларын куймаганнар. «Әгәр кирәк булса, җыелышта торып әйтербез», дигәннәр. Җыелышта хатның ялган булуы турында беркем дә авыз ачып сүз әйтмәде. Димәк, хаклык бар.

Райпоның өлкән яшьтәге, элекке хезмәтчәннәре сәүдә эшендәге үзгәрешләргә көенеп тә, уңай якларын күреп сөенеп тә язганнар хатны райкомның беренче секретарена.

«Без райподагы үзгәрешләрне күреп бер яктан шатлансак, икенче яктан борчылабыз. Элеккеге елларда (Идиятуллин җилкәсенә менеп утырып) райпо белән Дмитриевская һәм Горшкова командалык итте. Хәзер безгә үзебездә элек эшләп киткән яшь, энергияле М. М. Сафин килде. Райпоның кайбер кешеләре бу хәлгә шатланды, куллары акчага буялганнары көенде. Сафин гел командировкада —кайтып та керми: Әлмәт, Куйбышев, Мәскәү, Димитровград, Молдавия, Украина һәм башка урыннарда товар эзли, договор төзи, кайтарта. Гомумән, халык өчен янып-көеп йөри. Ләкин аңа аяк чалучылар күп алар —аның ярдәмчеләре. Шуны да әйтик: аның ярдәмчеләре Чванова кабинетында бикләнеп чит ил товарларын бүләләр, кием-салымнарны киеп-үлчәп карыйлар. Чванова бөтен дусларына шалтырата. Район Советы башкарма комитетыннан җаваплы хезмәткәрләр киләләр, кием-салым үлчиләр, туган көннәр үткәрәләр. Без әлеге кешеләрнең оятсызлыгына исебез китә. Хәлебездән килсә, алып ташлар идек. Нигә алар Чванованы якламасыннар, ул бит аларны киендерә. Ә «Галантерея» бүлегендәге акчаңы Чванова калдырткanны яхшы беләбез. Чванова командировкага бармый, товар эзләми, базага да бармый хәтта. Инде гаепләре ачылгач, бар гаепне Сафин өстенә аударырга тырышалар, тешләре-тырнаклары белән эштә калырга телиләр»,—диелгән хатта.

«Дөреслек халык ягында, ул акча корткычларына карата райпо идарәсе дөрес карар чыгарды. Намуслылар райкомга кеше өстеннән шикаять белән бармыйлар, дөреслекне эш белән күрсәтәләр. Бу хатны дөрес аңлап, халыкка җиткерерсез дип ышанабыз»,—дип тәмамлана хат.

Хат бераз кыскартылып бирелде. Шулай да анда язганнар халыкка аңлашылырлык.

Хатны укыгач, Хәлил Хәмзиевич исемнәре аталган кешеләрнең күтәрелеп халык алдында җавап бирүләрен сорады. Тик беркем дә урыныннан кузгалмады. Барысы райпоның баш бухгалтеры Александра Анисимовна Дмитриевская гына: «Мин кирәк әйберемне теләсә кайчан, теләсә каян алам», диде үзенең чыгышында.

Иптәш Морадыймов исеменә район китапханәсе хезмәткәрләре һәм китап укучылар исеменнән дә хат бар. Хатка күп имзалар куелган.

«Бүгенге «алтын эше» сәүдә эшенә булган бөтенхалык ризасызлыгына тагын бер тамчы булды. Соңгы атнада укучылар газетада бу мәсьәләнең объектив яктыртылуын көткәннәр иде. Кызганычка каршы, «Дуслык»та «02» хәбәреннән башка нәрсә күрмәдек.Ә бу халык арасында риза сызлык тудырды. Безнең карашка, халыкның ачуы чиктән ашкан. Әгәр мәйданга бер кеше чыкса, фетнә башлануын көт тор. Бар халык күтәреләчәк. Шәһәрдә дефициттан башкарма комитетның кайбер хезмәткәрләре һәм шәһәр «элитасы» гына файдалануы беркемгә дә сер түгел.

Без ревизиядән соң сатучыларның үз урыннарында булуларына гаҗәпләндек. Сәүдәнең барлык сферасында тәртип салуыгызны таләп

**(Ахыры 4 нче биттә).**

